Республика Татарстан

СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ

ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423370, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Янурыс авылы, Ленин ур., 43 а, тел.4-10-19 ИНН 1636001403 КПП 163601001 Р/С 40481050000057002З ОГРН 1031604000757 ОКАТО 92253884000

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 апрель 2016 ел № 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2013 елның 12 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре нигезендә һәм Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 ст., 7 ст. 19 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге халкының җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр бирү мәсьәләләре буенча фикерләрен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып,карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман районы, Янурыс авыл җирлеге, Янурыс авылы, Ленин урамы, 40 а адресы буенча урнашкан 16:36:050101:26 кадастр номеры булган «шәхси ярдәмче хуҗалык» алып бару өчен җир участогын, җитештерү һәм административ биналар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә рөхсәт ителгән файдалану төренә үзгәртергә.
2. «Росреестрның федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы буенча җир исәбенә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны махсус хинформация стендларында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М.М.Шәеховка йөкләргә.

Янурыс авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәдиева А.А.